ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

Статья 1

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6; 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты закон, муниципаль берәмлек уставы нигезендә турыдан-туры халык тарафыннан муниципаль сайлауларда сайланса, әлеге Кодекс күрсәтелгән вәкиллекле орган депутатларын һәм җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлауларны үткәрү тәртибен җайга сала.”;

2) 4 статьяның 8 өлешендә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3) 34 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3^1 өлеш өстәргә:

“3^1. Муниципаль берәмлекнең “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 2^1 өлеше нигезендә таратылган вәкиллекле органы депутаты булган затлар (муниципаль берәмлек вәкиллекле органының өч ай дәвамында тулы хокуклы утырышын үткәрмәгән өчен гаепсезлеге факты суд тарафыннан билгеләнгән затлардан тыш) күрсәтелгән хәлләргә бәйле рәвештә билгеләнгән сайлауларда кандидат итеп күрсәтелә алмый.”;

4) 39 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 2^1 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы таратылуга бәйле рәвештә билгеләнгән муниципаль берәмлек вәкиллекле органына сайлауларда әлеге орган депутаты булып торган һәм бу муниципаль берәмлек вәкиллекле органының өч ай дәвамында тулы хокуклы утырышын үткәрмәгән өчен гаепсезлеге факты суд тарафыннан билгеләнгән затлар арасыннан булган кандидат законлы көченә кергән күрсәтелгән суд карарын өстәмә рәвештә тапшырырга тиеш.”;

б) 1^1 өлешнең беренче абзацында “, муниципаль районнарның башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны” сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 40 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Кандидатлар исемлеге сайлауларны оештыручы комиссиягә сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле тарафыннан кәгазь чыганакта, ә Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда, сайлауларны оештыручы комиссия билгеләгән рәвештә, шулай ук машинадан укыла торган итеп тә тапшырыла, анда һәр кандидатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туу датасы һәм урыны, яшәү урынының адресы, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, паспортны яисә граждан паспортын алмаштыручы документны биргән органның исеме яисә коды, салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта), гражданлыгы, һөнәри белеме турында белем бирү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче оешма, аны тәмамлау елы һәм белеме, квалификациясе турында документның реквизитлары күрсәтелгән белешмәләр (булган очракта), төп эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаган очракта – шөгыль төре) күрсәтелә; әгәр кандидат депутат булса һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкарса, бу хакта белешмәләр тиешле вәкиллекле орган исемен күрсәтеп бирелә. Кандидат элек хөкем ителгән булса яисә хөкем ителүе гамәлдә булса, исемлекләрдә кандидатның хөкем ителгәнлеге турында белешмәләр күрсәтелә, хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган булса, хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган дата турында белешмәләр күрсәтелә. Кандидатның теләге белән исемлектә шулай ук кандидатның үзен тәкъдим иткән сәяси партиядә йә тавыш бирү көненә кадәр кимендә бер ел алдан законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән башка бердән артык булмаган иҗтимагый берләшмәдә торуы, бу сәяси партиядәге, иҗтимагый берләшмәдәге статусы күрсәтелә. Тапшырыла торган исемлек шулай ук әлеге Кодексның 37 статьясында билгеләнгән башка таләпләргә дә туры килергә тиеш.”;

б) 3 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) кандидатлар исемлегенә кертелгән һәр кандидатка карата – кандидатның керемнәре күләме турында һәм чыганаклары хакында, шулай ук кандидатның милек

хокукындагы (шул исәптән уртак милектәге) мөлкәте турында, банклардагы кертемнәре, кыйммәтле кәгазьләре хакында белешмәләрне. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 2^1 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы таратылуга бәйле рәвештә билгеләнгән муниципаль берәмлек вәкиллекле органына сайлауларда әлеге орган депутаты булып торган һәм муниципаль берәмлек вәкиллекле органының өч ай дәвамында тулы хокуклы утырышын үткәрмәгән өчен гаепсезлеге факты суд тарафыннан билгеләнгән затлар арасыннан булган кандидат законлы көченә кергән күрсәтелгән суд карарын өстәмә рәвештә тапшырырга тиеш.”;

6) 42 статьяда:

а) 2^1 өлештә “, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2^2 өлештә “, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны” сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 43 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күпмандатлы сайлау округында кандидатларны теркәү өчен кирәкле имзалар саны тиешле сайлау округы территориясендә теркәлгән, депутат мандатлары санына бүленгән сайлаучылар санының 0,5 процентын тәшкил итә, ләкин 10 имзадан да кимрәк була алмый.»;

8) 44 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләренә алмаштырырга;

9) 45 статьяда:

а) 3 өлешнең 1 пунктында “һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3^1 өлештә “, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен барлык документлар, әлеге Кодекста билгеләнгән очракларда, кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, башка затлар тарафыннан тиешле сайлау комиссиясенә Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар уздырганда тавыш бирү көненә кадәр 75 көннән алданрак булмаган вакытта һәм 45 көннән дә соңга калмыйча 18 сәгатькә кадәр яисә җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән алданрак булмаган вакытта һәм 40 көннән дә соңга калмыйча 18 сәгатькә кадәр берьюлы тапшырыла. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатны теркәү өчен барлык документлар, әлеге Кодекста билгеләнгән очракларда, кандидат, башка затлар тарафыннан Үзәк сайлау комиссиясенә тавыш

бирү көненә кадәр 55 көннән алданрак булмаган вакытта һәм 45 көннән дә соңга калмыйча 18 сәгатькә кадәр берьюлы тапшырыла.";

10) 46 статьяда:

а) 7 өлештә "һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 8 өлештә "шәһәр округы, җирлек башлыгын һәм" сүзләрен "шәһәр округының, җирлекнең" сүзләренә алмаштырырга, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына" сүзләрен "Дәүләт Советы депутатларын" сүзләренә алмаштырырга;

11) 47 статьяда:

а) 6 өлештә:

1^2 пунктта ", муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны" сүзләрен төшереп калдырырга;

7^1 пунктта "һәм (яисә) муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 2^3 пункт өстәргә:

"2^3) сайлаучыларның кандидатлар исемлеген теркәү өчен тапшырылган дөрес имзаларының саны җитәрлек булмау;";

12) 52 статьяның 1 өлешендә "сайланулы вазыйфаи зат" сүзләрен "җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты" сүзләренә алмаштырырга;

13) 66 статьяда:

а) 4 өлештә "Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп" сүзләрен "Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп" сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 өлештә "сайлаучыларның саны ике йөз мең кешедән арткан муниципаль берәмлекләрдә" сүзләрен "Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Башка сайлаулар үткәргәндә кулланыла торган бюллетеньнәр, махсус билгеләр (маркалар) сатып алу тиешле сайлауларны оештыра торган комиссия тарафыннан Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.";

14) 67 статьяның 14 өлешендәге 14 пунктына ", шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар" сүзләрен өстәргә;

15) 69 статьяда:

а) 3 өлештә "Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп" сүзләрен "Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп" сүзләренә алмаштырырга, "бу

акчаларның тотылуын” сүзләреннән соң “, шул исәптән һәр операция буенча,” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәргә:

“4. Махсус сайлау счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:

1) тиешле сайлау фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;

2) тиешле сайлау фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;

3) тиешле сайлау фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;

4) иганәчеләргә тиешле сайлау фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;

5) тиешле сайлау фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.”;

16) 72 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“72 статья. **Контроль-ревизия хезмәтләре**

1. Сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның сайлау фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, кандидатларның, сайлау берләшмәләренең финанс хисапларын тикшерү өчен, кандидатларның әлеге Кодексның 39 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты һәм 1^1 өлеше нигезендә мөлкәте турында, керемнәре хакында, аларның чыганаклары турында һәм чыгымнары хакында тапшырган белешмәләрнең дөреслеген, кандидатлар тарафыннан әлеге Кодексның 39 статьясындагы 1^3 өлешендә, 40 статьяның 3^3 өлешендә, 41 статьяның 1^3 өлешендә һәм 42 статьяның 2^2 өлешендә каралган таләпләрнең үтәлүен тикшерүне оештыру өчен түбәндәге контроль-ревизия хезмәтләре төзелә:

1) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча округ сайлау комиссияләре каршындагы контроль-ревизия хезмәте;

3) муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре каршындагы контроль-ревизия хезмәте;

4) җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ сайлау комиссияләре каршындагы контроль-ревизия хезмәте.

2. Контроль-ревизия хезмәтләре дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр тиешле сайлау комиссиясе таләбе буенча, сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне комиссияләр карамагына җибәрергә тиеш. Бу чакта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына белгечләр кимендә биш айга, ә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карамагына кимендә ике айга җибәрелә.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтләрендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала, аларга шулай ук сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә акчалата бүләкләүләрне түләү тәртибен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.

4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый һәм матди-техник тәэмин итү тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәрелгәндә контроль-ревизия хезмәте тиешле сайлау комиссиясе кушуы буенча:

1) сайлау фондлары төзегән сайлау берләшмәләренең, кандидатларның, түбәнгерәк сайлау комиссияләренең финанс хисапларын тикшерә;

2) кандидатларның, аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында һәм мөлкәте хакында, әлеге керемнәрнең чыганаклары турында, кандидатларның, аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында, кандидатларның акчалата кертемнәре һәм кыйммәтле кәгазьләре, шул исәптән акцияләре һәм кандидатларның коммерциягә караган оешмалар капиталында башкача катнашуы турында, кандидатларның, аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының Россия Федерациясе территориясеннән читтәге мөлкәте, шул исәптән ышанычлы идарәгә тапшырылганнары турында, кандидатларның әлеге Кодексның 39 статьясындагы 1^3 өлешендә, 40 статьясындагы 3^3 өлешендә, 41 статьясындагы 1^3 өлешендә, 42 статьясындагы 2^2 өлешендә каралган таләпләрне үтәве хакында, мөлкәти

характердагы башка йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген тикшерүне оештыра;

3) сайлау берләшмәләренең, кандидатларның сайлау алды агитациясен үткәрүне, сайлауларга турыдан-туры бәйле башка чараларны гамәлгә ашыруны финанслауның билгеләнгән тәртибе үтәлешен тикшереп тора;

4) сайлау берләшмәләреннән, кандидатлардан, шулай ук сайлау комиссияләреннән үз компетенциясенә керә торган барлык мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып ала;

5) федераль башкарма хакимият органнарына, башка дәүләт органнарына, милек рәвешенә бәйсез рәвештә оешмаларга, шулай ук гражданнарга үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итә, сайлауларны финанс белән тәэмин итүгә бәйле кирәкле белешмәләрне һәм материалларны соратып ала. Контроль-ревизия хезмәте мөрәҗәгатьләренә җаваплар һәм ул сораган материаллар ун көн эчендә, ә тавыш бирү көненә кадәр биш һәм аннан да азрак көн калган очракта һәм тавыш бирү көнендә кичекмәстән тапшырыла;

6) сайлауларны финанслаганда җибәрелгән хокук бозулар турында документлар тутыра;

7) тиешле сайлау комиссиясе алдында тиешле сайлау кампанияләрен финанслаганда сайлау берләшмәләре, кандидатлар, шулай ук гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан җибәрелгән хокук бозулар өчен аларга җаваплылык чаралары куллану турындагы мәсьәләне күтәрә;

8) тикшерүләр үткәрү, бәяләмәләр әзерләү һәм эксперт бәяләүләре өчен экспертлар җәлеп итә.

6. Контроль-ревизия хезмәте үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда “Сайлаулар” ДАСтан файдаланырга мөмкин.”;

17) 73 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

“10. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда әлеге бинага инвалид булган сайлаучылар тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.”;

18) 75 статьяда:

а) 11 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Җирле үзидарә органнарына сайлауларда “Барлык кандидатларга каршы” (“Кандидатлар исемлекләренең барысына да каршы”) юлы сайлау бюллетенендә булмый.”;

б) 14 өлештә “аларны әзерләүгә заказ биргән” сүзләрен “аларны сатып алган” сүзләренә, “Заказга” сүзен “Контрактка” сүзенә, “Бюллетеньнәр әзерләүгә заказ биргән” сүзләрен “Бюллетеньнәр сатып алган” сүзләренә алмаштырырга;

в) 15 өлештә “Бюллетеньнәр әзерләүгә заказ биргән” сүзләрен “Бюллетеньнәр сатып алган” сүзләренә алмаштырырга;

19) 104^4 статьяда:

а) 1 өлештә “һәм (яисә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының”, “һәм муниципаль сайлауларда сайланган һәм әлеге карарны кабул итү көненә шушы муниципаль берәмлекләрнең эшләп килүче башлыклары саныннан” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә “һәм (яисә) муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары”, “һәм әлеге карарны кабул итү көненә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының муниципаль сайлауларда сайланган һәм эшләп килүче башлыклары саныннан” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

г) 4 өлештә “һәм (яисә) муниципаль берәмлек башлыгы сайланмаган”, “һәм (яисә) шушы муниципаль берәмлек башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 өлештә “һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 7 өлештә икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Кандидатны хуплау кәгазендә шулай ук муниципаль берәмлек вәкиллекле органының имза салучы депутатының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм туу датасы; имза салучы зат депутат булган муниципаль берәмлек вәкиллекле органының исеме; муниципаль берәмлек исеме күрсәтелә.”;

ж) 8 өлештә “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 9 өлештә “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

и) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11. Кандидат, аның яшәү урыны турындагы күрсәткечләр, шулай ук муниципаль берәмлек вәкиллекле органының имза салучы депутаты турындагы күрсәткечләр, имза салучы зат депутат булган муниципаль берәмлек вәкиллекле органының исеме кандидатны хуплау кәгазенә машинкада басып яисә кулдан язып кертелергә мөмкин. Бу чакта карандаш белән язу рөхсәт ителми. Имзасын, аны кую датасын һәм вакытын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты үз кулы белән яза. Кандидатны хуплау кәгазендәге имзаның хаклыгы нотариаль тәнкыйтләнергә тиеш. Законда каралган очракларда кандидатны хуплау кәгазендәге имзалар җирле үзидарә органының нотариаль гамәлләр башкарырга вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан тәнкыйтләнергә мөмкин. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тарафыннан үз имзасын кире алу рөхсәт ителми.”;

к) 12 өлештә “яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга;

л) 13 өлештә “, муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

м) 14 өлештә “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары” сүзләрен төшереп калдырырга;

н) 15 өлештә “һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары”, “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары” сүзләрен төшереп калдырырга;

20) 104^5 статьяда:

а) 1 өлештә “һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 өлештә “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 5 өлештә “сораштыру уздырырга хокуклы” сүзләрен “сораштыру уздыра” сүзләренә алмаштырырга; “яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 өлештә:

1 пунктта “яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта “яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга, “имза салган” сүзтезмәсе татар телендәге текстта үзгәрешсез кала;

6 пунктта “, яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 өлештә “һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 10 өлешнең икенче абзацында “, муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлек башлыгының” сүзләрен төшереп калдырырга;

21) 108 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11) округ комиссияләре төзелмәгән йә аларның вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә башка комиссияләргә йөкләнмәгән очракларда округ комиссияләре вәкаләтләрен башкара”;

б) 20 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

22) 108^1 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

“5. Округ комиссияләре төзелмәскә дә мөмкин. Бу очракта округ комиссиясе вәкаләтләрен муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карары белән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе яисә участок комиссиясе башкарырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән карары буенча округ комиссиясе вәкаләтләре территориаль комиссиягә йөкләнергә мөмкин.”;

23) 117 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

24) 132 статьяның 2^1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2^1. Әлеге Кодексның 60 статьясындагы 13 өлеше нигезләмәләре “Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 28 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көннән соң билгеләнгән сайлауларда депутатлары сайланган чакырылыштан соң килгән чакырылышларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларны үткәрүгә бәйле барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.”;

25) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ КОДЕКСНЫҢ 78 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1 күбрәк яисә тигез	3 + 5 + 6
2 тигез	– 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13
8 + 9 тигез	10 + 11
11 тигез	14 + беркетмәнең калган барлык юллары”;

26) 10 нчы кушымтада “вазыйфасын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгы”, “яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы” сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

“Татарстан Республикасы референдумы турында” 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 6 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Инициатив төркемнең үтенечнамәсенә күрсәтелгән төркемнең барлык әгъзалары имза салырга тиеш, ә референдум үткәрү инициативасы белән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә чыккан очракта, үтенечнамәгә әлеге сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең җитәкче органының йә аның референдум үткәрү инициативасы белән чыгу турындагы карарны хуплаган региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе җитәкче органының барлык әгъзалары имза салырга тиеш.”;

2) 43 статьяның 6 пунктында “Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп” сүзләренә алмаштырырга;

3) 44 статьяда:

а) 5 пунктның “о” пунктчасына “, шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар” сүзләрен өстәргә;

б) 10 пунктта “Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп” сүзләренә алмаштырырга, “аларны тоту турында” сүзләреннән соң “, шул исәптән һәр операция буенча,” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 өлешләр өстәргә:

“11. Референдум фондының махсус счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:

а) тиешле референдум фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;

б) тиешле референдум фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;

в) тиешле референдум фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;

г) иганәчеләргә референдум фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;

д) тиешле референдум фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.

12. Әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.”;

4) 46 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“46 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте**

1. Референдум әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның референдум фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, инициатив төркемнең финанс хисабын тикшерү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә.

2. Контроль-ревизия хезмәте дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы филиалы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе таләбе буенча, референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына җибәрергә тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына белгечләр кимендә биш айга җибәрелә.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала, аларга шулай ук референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин.

4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый, матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда контроль-ревизия хезмәте “Сайлаулар” ДАС тан файдаланырга мөмкин.”;

5) 47 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

“9. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда референдумда катнашучы инвалидлар әлеге бинага тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.”;

6) 49 статьяның 7 пунктында “Заказга” сүзен “Контрактка” сүзенә алмаштырырга;

7) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 52 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1 күбрәк яисә тигез	3 + 5 + 6
2 тигез	3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13
8 + 9 тигез	10 + 11
11 тигез	14 + беркетмәнең калган барлык юллары”.

3 статья

“Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 5 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Инициатив төркемнең үтенечнамәсенә күрсәтелгән төркемнең барлык әгъзалары имза салырга тиеш, ә референдум үткәрү инициативасы белән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә чыккан очракта үтенечнамәгә әлеге сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең җитәкче органының йә аның референдум үткәрү инициативасы белән чыгу турындагы карарны хуплаган региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе җитәкче органының барлык әгъзалары имза салырга тиеш.”;

2) 45 статьяның 6 пунктында “Татарстан Республикасы Милли банкы белән килешеп” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп” сүзләренә алмаштырырга;

3) 46 статьяда:

а) 5 пунктның “о” пунктчасына “, шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар” сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктта “Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп” сүзләренә алмаштырырга, “тоту турында” сүзләреннән соң “, шул исәптән һәр операция буенча,” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 өлешләр өстәргә:

“12. Референдум фондының махсус счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:

а) тиешле референдум фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;

б) тиешле референдум фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;

в) тиешле референдум фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;

г) иганәчеләргә референдум фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;

д) тиешле референдум фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.

13. Әлеге статьяның 12 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.”;

4) 48 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“48 статья. **Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе контроль-ревизия хезмәте**

1. Референдум әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның референдум фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, инициатив төркемнең финанс хисабын тикшерү өчен муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә.

2. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы филиалы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе таләбе буенча, референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карамагына җибәрергә тиеш. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карамагына белгечләр кимендә ике айга җибәрелә.

3. Әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала, аларга шулай ук референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин.

4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый, матди-техник тәэмин итү муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда контроль-ревизия хезмәте “Сайлаулар” ДАС тан файдаланырга мөмкин.”;

5) 49 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

“9. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда референдумда катнашучы инвалидлар әлеге бинага тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.”;

6) 51 статьяның 7 пунктында “Заказга” сүзен “Контрактка” сүзенә алмаштырырга;

7) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 54 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1 күбрәк яисә тигез	3 + 5 + 6
2 тигез	3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13
8 + 9 тигез	10 + 11
11 тигез	14 + беркетмәнең калган барлык юллары”.

4 статья

“Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында” 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 39 статьяның 4 өлешендә “Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан

Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп” сүзләренә алмаштырырга;

2) 40 статьяда:

а) 5 өлешнең 14 пунктына “, шулай ук чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциягә карамаган оешмалар” сүзләрен өстәргә;

б) 13 өлештә “Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп” сүзләрен “Россия Федерациясе Үзәк банкының Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе белән килештереп” сүзләренә алмаштырырга, “акчаларны тотуны” сүзләреннән соң “, шул исәптән һәр операция буенча,” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 өлешләр өстәргә:

“14. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетына акчалар керү һәм әлеге акчаларның тотылуы турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштыра. Түбәндәге белешмәләрне урнаштыру мәҗбүри:

1) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондыннан акчаларның тотылуы буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 50 мең сумнан артык булса;

2) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына 25 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары күчергән юридик затлар турында;

3) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына 20 мең сумнан артык ихтыярый иганә акчалары керткән гражданнарның саны турында;

4) иганәчеләргә тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондыннан кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән кире кайтару нигезләре хакында;

5) тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм тотылган акчаларның гомуми суммасы турында.

15. Чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрелгәндә әлеге статьяның 14 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән күләмдә гамәлгә ашырыла.”;

3) 42 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“42 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру өчен комиссияләргә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, акчаларның чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына керү чыганакларын, әлеге акчаларны һәм алардан файдалануны исәпкә алуны оештыруны тикшереп тору, инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс хисабын тикшерү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршында контроль-ревизия хезмәте төзелә.

2. Контроль-ревизия хезмәте дәүләт органнарыннан һәм башка органнардан, оешмалардан һәм учреждениеләрдән, моңа Россия Федерациясе Үзәк банкының

Татарстан Республикасында территориаль учреждениесе һәм Россия Федерациясе Саклык банкы филиалы да керә, белгечләрне (шул исәптән җитәкчеләрне) җәлеп итеп төзелә. Күрсәтелгән органнар һәм учреждениеләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе таләбе буенча, чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белгечләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карамагына кимендә биш айга җибәрергә тиеш.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән белгечләр контроль-ревизия хезмәтендә эшләү чорына төп эшләреннән азат ителә, аларның эш урыны (вазыйфасы), төп эш урыны буенча билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала, аларга шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирү әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән акчалата бүләкләүләр бирелергә мөмкин.

4. Контроль-ревизия хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Контроль-ревизия хезмәте эшчәнлеген оештыру, хокукый, матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда контроль-ревизия хезмәте “Сайлаулар” ДАС тан файдаланырга мөмкин.”;

4) 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

“10. Тавыш бирү бинасын җиһазлаганда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы инвалидлар әлеге бинага тоткарлыксыз кереп тавыш бирсен өчен Россия Федерациясе законнарында каралган шартлар тәэмин ителергә тиеш. Тавыш бирү үткәрелгәндә мондый затларның актив сайлау хокукын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законда, башка федераль законнарда каралган таләпләрне үтәп, аларга булышлык күрсәтелә.”;

5) 45 статьяның 7 өлешендә “Заказга” сүзен “Контрактка” сүзенә алмаштырырга;

6) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Президентын
чакыртып алу тәртибе турында”
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 48 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

1 күбрәк яисә тигез	3 + 5 + 6
2 тигез	3 – 4 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13
8 + 9 тигез	10 + 11
11 тигез	14 + беркетмәнең калган барлык юллары”;

5 статья

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көченә керүнең башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 17 пункты, 2 статьясындагы 5 пункты, 3 статьясындагы 5 пункты һәм 4 статьясындагы 4 пункты 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 8 мае
№ 34-ТРЗ